Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районы
Югары Чура авыл җирлеге Советы

РЕШЕНИЕ

2021 елның 24 сентябре №24

Югары Чура авыл җирлеге Советының 2007 елның 17 октябрендәге 31 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районының Югары Чура авыл җирлегендә гражданнардан сорашып белешүне билгеләү һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Кукмара муниципаль районының Югары Чура авыл җирлегендә гражданнардан сорашып белешүне билгеләү һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәне «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатларында Югары Чура авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Югары Чура авыл җирлеге Советының 2007 елның 17 октябрендәге 31 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районының Югары Чура авыл җирлегендә гражданнардан сорашып белешүне билгеләү һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә:

а) 8 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Гражданнардан сорашып белешүне билгеләү турындагы карар Югары Чура авыл җирлеге Советы тарафыннан кабул ителә. Гражданнар арасында сораштыру үткәрү өчен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге муниципаль берәмлекнең рәсми сайты файдаланылырга мөмкин. Гражданнардан сораштыруны билгеләү турындагы карарда түбәндәгеләр билгеләнә:

1) сораштыру уздыру датасы һәм сроклары;

2) сораштыру уздырганда тәкъдим ителә торган сорауны (сорауларны) формулировкалау;

3) сораштыру үткәрү методикасы;

4) сораштыру кәгазенең формасы;

5) сораштыруда катнашучы муниципаль берәмлек халкының минималь саны;

6) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтыннан файдаланып гражданнардан сораштыру үткәрелгән очракта, сораштыруда катнашучыларны идентификацияләү тәртибе.

б) 19 статьяның 1 пунктында «яисә муниципаль берәмлек халкы» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Җирлек башлыгы В.Н. Андреев